Төрки халыкларның
XVI «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Нигезләмә Төрки халыкларның «Нәүрүз» Халыкара театр фестиваленең (алга таба - Фестиваль) үткәрү тәртибен, максатларын, бурычларын һәм вакытын билгели.

1.2. Фестиваль 2025 елның 9-22 июнендә Казан шәһәрендә уздырыла.

1.3. Фестиваль билгеле бер темага багышланырга һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән максатлары һәм бурычлары кысаларында фестивальнең тематик юнәлешен чагылдырган чаралар белән (спектакльләр, күргәзмәләр, иҗади очрашулар, концертлар һ.б.) үрелеп барырга мөмкин.

1.4. Фестивальнең үткәрү вакыты, темасы, финанслау тәртибе Оештыручы тарафыннан билгеләнә һәм Нигезләмәдә билгеләнгән максатлары һәм бурычлары кысаларында Гамәлгә куючы белән килештерелә.

2. Фестивальнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Фестивальнең максатлары:

2.1.1. Төрки халыклар театрларының иҗади төрлелеген халыкара дәрәҗәдә тәкъдир итү;

2.1.2. Төрки дөнья театрларының сәнгати үзенчәлеген күрсәтү;

2.1.3. Төрки театрларның бердәм мәгълүмати һәм иҗади мөһитен булдыру;

2.1.4. Төрки телле һәм Россия Федерациясенең һәм дөньяның башка милли театрларының стратегик үсеше, иҗади коммуникациясе һәм партнерлыгы юлларын билгеләү.

2.2. Фестивальнең бурычлары:

2.2.1. Театр сәнгатенең милли формаларын үстерү һәм театр эшлеклеләренең иҗади инициативаларына этәргеч бирү;

2.2.2. Төрки һәм башка халыкларның театраль җәмгыятьләрендә катнашучыларны арттыру;

2.2.3. Профессиональ аралашу һәм иптәшләрчә мөнәсәбәтләр, уртак иҗади проектлар булдыру өчен шартлар тудыру;

2.2.4. Театр җәмәгатьчелегенең театраль процессның яңа заманча формаларына игътибарын җәлеп итү;

2.2.5. Россия Федерациясендә яшәүче төрки һәм башка халыкларның телләрен популярлаштыру, саклау һәм үстерү;

2.2.6. Төрки халыклар театрларын халыкара театр процессына якынайту;

2.2.7. Төрки халыклар театрларының халыкара һәм бөтенроссия элемтәләрен үстерү һәм ныгыту;

2.2.8. Төрки халыклар театрларының эстетика дәрәҗәсен һәм куелыш культурасын күтәрү.

3. Фестивальне гамәлгә куючы, оештыручы һәм партнерлар

3.1. Фестивальне гамәлгә куючы - Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Гамәлгә куючы).

3.2. Фестивальне оештыручы - Дәүләт бюджет учреждениесе «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» (алга таба – Оештыручы).

3.3. Фестиваль Партнерлары:

3.3.1. «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешмасы;

3.3.2. «Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» Гомумроссия иҗтимагый оешма бүлеге - «Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге» (алга таба – ТРның Театр эшлеклеләре берлеге);

3.3.3. Дәүләт бюджет учреждениесе «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» (алга таба – Партнер театр);

3.3.4. Дәүләт бюджет учреждениесе «Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры» (алга таба – Партнер театр);

3.3.5. Дәүләт бюджет учреждениесе «Әкият» Татар дәүләт курчак театры» (алга таба – Партнер театр).

3.3.6. Тиешле килешүләр төзү аша Оештыручы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнгән учреждениеләр һәм оешмалар.

4. Фестиваль Дирекциясе

4.1. Фестивальне әзерләү, оештыру һәм үткәрү мәсьәләләрен оператив хәл итү өчен Оештыручы Фестиваль Дирекциясе төзи һәм раслый; карарын Протокол белән беркетә.

4.2. Дирекциянең составы (эшчәнлекнең барлык өлкәләре өчен дә җаваплы) Оештыручы тарафыннан гаризалар кабул ителә башлаганчы 7 көн алдан раслана.

4.3. Дирекция фестивальнең темасын билгели, мәгълумат һәм PR ярдәме күрсәтә, гариза формасын раслый, гаризалар җыя, катнашучыларны сайлый, катнашучылар санын билгели, программа һәм афиша төзи, фестиваль чараларын югары сәнгать һәм оештыру дәрәҗәсендә үткәрүне тәэмин итүче учреждение һәм оешмалар белән сөйләшүләр алып бара.

4.4. Фестиваль Дирекциясе карарлары килгән әгъзаларның күпчелек тавыш бирүе аша коллегиаль рәвештә кабул ителә һәм беркетмә нигезендә рәсмиләштерелә.

4.5. Дирекция беркетмәсе Фестивальнең сәнгать җитәкчесе һәм Дирекция рәисе тарафыннан раслана, имзалана һәм Фестиваль Дирекциясе архивларында саклана.

4.6. Фестиваль Дирекциясе Катнашучы белән килешенеп, Фестивальнең игълан ителгән техник характеристикалары һәм расланган программасы нигезендә Татарстан Республикасы театраль тамаша һәм/яки мәдәни-ял итү учреждениеләре мәйданчыкларында фестиваль чараларын вакытында күрсәтүне оештыра.

4.7. Фестиваль Дирекциясе Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән Фестивальне уздыру вакыты дәвамында уйналган спектакльләрнең өзлексез күрсәтелүен тәэмин итә һәм техник җитешсезлекләрне җайга сала.

4.8. Фестиваль Дирекциясе Фестивальнең төп программасы спектакльләрендә Тәнкыйтьчеләр Коллегиясе һәм рәсми делегацияләр әгъзаларының, Фестиваль кунакларының булуын тәэмин итә.

5. Фестивальдә катнашучылар

5.1. Фестивальдә катнашалар:

5.1.1. Төрки телле республикалар һәм илләрнең профессиональ дәүләт һәм бәйсез драма һәм курчак театрлары;

5.1.2. Төрки халыкларның традицион мәйданчык театраль формасындагы спектакльләр башкаручы коллективлар (ачык һавада башкарылучы спектакльләр, шул исәптән, сайт-специфика, променад жанрларындагы спектакльләр дә булырга мөмкин).

5.2. Фестивальдә катнашучы спектакльләрне сайлап алу критерийлары:

5.2.1. Фестивальдә премьералары Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән Фестивальне үткәрү датасына кадәр соңгы ике театр сезонында узган спектакльләр катнаша ала.

5.2.2. Фестивальгә тәкъдим ителгән барлык спектакльләр дә төрки телләрдә башкарылырга тиеш. Фестиваль темасы кысаларында (әлеге Нигезләмәнең 1.3. пункты буенча) һәм фестиваль кунагы буларак чакырылган театр коллективларының спектакльләре искәрмә булып тора.

5.2.3. Фестивальнең төп программасында катнашучы коллективның саны драма театрлары өчен 30 кешедән, курчак һәм урам театрлары өчен 20 кешедән артмаска тиеш.

5.2.4. Коллективның саны Нигезләмәдә билгеләнгән саннан арткан очракта, Катнашучы әлеге саннан арткан кешеләр өчен чыгымнарны үз хисабына түли.

5.2.5. Партнер театрлар фестиваль спектакльләрен күрсәтү өчен үз мәйданчыкларын бушлай тәкъдим итәләр.

5.2.6. Партнер театрлар спектакльләре фестиваль программасына, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән спектакльгә карата таләпләрне исәпкә алып, Фестиваль Дирекциясе карары белән кертелә.

5.2.7. Фестивальдә катнашучы Татарстан Республикасы татар театрларын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Тантана» театраль премиясе комиссиясе соңгы ике театр сезоны йомгаклары буенча билгели. Алар арасында ике драма һәм бер курчак театры спектакльләре булырга мөмкин.

5.2.8. Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән килгән татар театрлары Нигезләмәнең 6.1 пункты нигезендә катнаша.

6. Фестивальне үткәрү тәртибе

6.1. Фестивальнең темасы Фестиваль Дирекциясе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 1.3. пункты нигезендә төзелә. Фестивальне үткәрү турында актуаль мәгълүмат заявкалар кабул итә башлаганчы бер ай кала Оештыручының рәсми сайтында урнаштырыла.

6.2. Фестивальдә катнашучыларны сайлап алу һәм программаны төзү эшләрен Фестиваль Дирекциясе башкара.

6.3. Фестивальнең төп программасына драма, курчак, урам һәм кросс-жанр спектакльләре сайлап алынырга мөмкин.

6.4. Фестивальнең төп программасында катнашу өчен 2022 елның 15 декабреннән 2023 елның 1 февраленә кадәр Оештыручының рәсми сайтында урнаштырылган, Фестиваль Дирекциясе тарафыннан расланган форма буенча гариза тутырыла: kamalteatr.ru/projects.

6.5. Фестиваль төп программадан тыш театр коллективының бер спектаклен фестиваль кунагы сыйфатында күрсәтүне күздә тота;

6.6. Фестиваль Дирекциясе фестиваль афишасын Оештыручының рәсми сайтында www.kamalteatr.ru фестиваль башланганчы бер айдан да соңга калмыйча урнаштыра.

6.7. Дирекция гаризалар кабул итү вакытын үзгәртә ала. Бу хакта Оештыручының рәсми сайтында игълан итә һәм үз карарын Беркетмә рәвешендә раслый.

6.8. Фестиваль турында мәгълүмат алу өчен Фестиваль Дирекциясенә түбәндәге адреслар буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин: Телефон номеры +7 (843) 293-06-38; e-mail адрес nauruz@kamalteatr.ru.

7. Тәнкыйтьчеләр коллегиясе

7.1. Фестиваль спектакльләре турында фикер алышу һәм күзәтүләр язу өчен Россия һәм чит илләрдән театр тәнкыйтьчеләре чакырыла. Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең составы Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге белән килешенеп төзелә һәм Фестиваль Дирекциясе тарафыннан раслана.

7.2. Фестиваль Дирекциясе катнашучыга фестиваль спектаклен Тәнкыйтьчеләр коллегиясе тарафыннан карау һәм фикер алышу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

7.3. Фестивальдә катнашучы Фестиваль Дирекциясенә фестиваль башланырга 10 көн кала Тәнкыйтьчеләр коллегиясе тарафыннан спектакль буенча фикер алышырга әзер булуы турында хәбәр итәргә тиеш.

7.4. Фестивальнең төп программасыннан тыш булган спектакльләр турында фикер алышу, театр коллективы җитәкчелеге һәм Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең үзара килешүе буенча оештырыла.

8. Фестиваль кунаклары

8.1. Фестиваль кунагы статусына ия була ала:

8.1.1. Фестивальнең төп программасыннан тыш чыгыш ясаучы театр сәнгате өлкәсендә танылган театр коллективы;

8.1.2. Чакырылган рәсми делегацияләр әгъзалары;

8.1.3. Күренекле театр эшлеклеләре.

9. Фестивальне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту

9.1. Фестивальгә әзерлекне, аның барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту өчен Фестиваль Дирекциясе тарафыннан Матбугат хезмәте оештырыла.

9.2. Фестивальдә катнашучы журналистлар һәм корреспондентлар фестиваль башланырга 10 көннән дә соңга калмыйча фестивальнең матбугат хезмәтендә аккредитацияләнергә тиеш.

9.3. Фестивальнең матбугат үзәге:

9.3.1. Фестивальнең барлык чараларында журналистларның һәм корреспондентларның катнашуын тәэмин итә;

9.3.2. Фестивальдә катнашучылар белән Матбугат конференцияләре, Тәнкыйтьчеләр коллегиясе һәм Фестиваль Дирекциясе белән йомгаклау Матбугат конференциясе оештыра;

9.3.3. Фестивальнең анонслары һәм рекламасы урнаштырылган махсус газета чыгарылышларын басмага әзерли;

9.3.4. Фестивальне таныту максатларында массакүләм мәгълүмат чаралары өчен спектакльләр буенча фикер алышуларның барышы турында һәм фестиваль нәтиҗәләре буенча отчёт әзерли.

10. Финанслау тәртибе

10.1. Фестиваль Гамәлгә куючы һәм Оештыручы финанс чаралары хисабына үткәрелә.

10.2. Гамәлгә куючы килешүе нигезендә һәм Оештыручы карары буенча финанс чаралар Фестивальне әзерләүгә һәм үткәрүгә тотыла.

10.3. Оештыручы Фестиваль кунакларына һәм Тәнкыйтьчеләр Коллегиясенә Россия Федерациясе территориясенә керү өчен кирәкле виза һәм башка документларны рәсмиләштерү чыгымнарын түли.

10.4. Оештыручы Фестивальнең төп программасында катнашучыларның 3 көн дәвамында һәм һәр театр коллективыннан 5 кешедән торган рәсми

делегация әгъзаларының Фестивальнең барлык көннәре дәвамында (Нигезләмәнең 1.2 пунктында билгеләнгән) яшәве өчен түли.

10.5. Оештыручы фестивальне үткәрү кысаларында спектакльне күрсәткән коллективка яки катнашучының спектаклен күрсәтүне оештыручы затка гонорар түли.

10.6. Күрсәтелгән спектакль өчен гонорар күләмен Фестиваль дирекциясе билгели һәм үз карарын беркетмә белән раслый.

10.7. Катнашучы фестиваль үткәрү урынына бару һәм сәхнә бизәлешен (декорацияләр, костюмнар, реквизит һ.б.) күчерү белән бәйле чыгымнарны мөстәкыйль түли.

10.8. Оештыручы фестивальнең һәр катнашучысы белән Фестивальдә катнашуның оештыру, техник һәм финанс шартлары теркәлгән килешү төзи.

10.9. Оештыручы Фестиваль кунакларына фестивальне уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, Казан шәһәренең кунакханәсеннән/кунакханәсенә кадәр трансфер һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли.

10.10. Оештыручы Фестиваль кунагына Фестиваль кысаларында күрсәтелгән спектакле өчен гонорар түләүне күздә тота. Гонорарның күләме һәм түләү шартлары Фестиваль кунагы белән Оештыручы арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

10.11. Оештыручы Тәнкыйтьчеләр коллегиясенең фестивальне уздыру шәһәренә кадәр бару һәм кире кайту, Казан шәһәренең кунакханәсеннән/кунакханәсенә кадәр трансфер, кунакханәдә яшәү һәм туклану белән бәйле чыгымнарны түли. Тәнкыйтьчеләр коллегиясе әгъзаларының эше өчен түләү Фестиваль сметасы нигезендә башкарыла.

10.12. Оештыручы Фестивальдә катнашучы Тәнкыйтьчеләр коллегиясенә гонорар түләүне күздә тота.

10.13. Фестиваль спектакльләрен күрсәтү өчен үз мәйданчыкларын тәкъдим иткән Партнер-театрларга гонорар түләнми.

10.14. Фестиваль чараларына билетлар сатудан кергән акча Фестивальне үткәрү чыгымнарын каплауга тотыла.